# И, ХОДАЙ, ИСӘНЛЕК БИР...

**Рамиль Чурагулов сүзләре** **Ризван Хәким музыкасы**






## И, ХОДАЙ, ИСӘНЛЕК БИР...

1. Кешегә гомерләр бирелә
Мең түгел бары тик бер генә.
Кулымнан төшермәм мин сине
Җаныем төшермәм гомергә.

*Кушымта:* Мин сине ташламам мәңгегә-мәңгегә
Шул ачы язмышлар кулына.
Ташламам беркайчан, беркайда, беркемгә
И, Ходай, исәнлек бир син миңа.

2. Тиз үтә бу тормыш язлары,
Ә алда салкыны карлары.
Мин сине өшетмәм, туңдырмам
Дөньяда онытма мин барын.

*Кушымта:* шул ук.

3. Без икәү бербөтен син дә мин,
Кайгы да, шатлык та гел уртак.
Йөрәкләр мәңгегә бәйләнгән
Мәхәббәт мәңгелек табышмак.

*Кушымта:* Мин сине ташламам мәңгегә-мәңгегә,
Шул ачы язмышлар кулына.
Ташламам беркайчан, беркайда, беркемгә
И, Ходай, исәнлек бир син миңа.
Бәхетле булырга килгәнбез бу җиргә
И, Ходай, исәнлек бир син безгә.